ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.09.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1829**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территорияләрне социаль, икътисадый, экологик һәм башка факторлардан чыгып билгеләү максатларында, авыл җирлеге территориясенең тотрыклы үсешен тәэмин итү, бу территориянең комплексы үсешен уңайлы тормыш шартлары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.
2. Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча комиссия төзергә, аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган тәртиптә комиссиягә 2020 елның 31 октябренә кадәр Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү эшләрен башкарырга.
5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү турында хәбәр урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

ЗМР Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
25.09.2020 ел , №1829

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАН ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА**
**КОМИССИЯ СОСТАВЫ**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Старостин А. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Сергеев П.Н. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе » МБУ җитәкчесе |

**Комиссия секретаре:**

| | |
|---|---|
| Левочкина Н.Н. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ бүлеге начальнигы; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Минһаҗев М. Р. | Олы Карагужа авыл җирлеге башлыгы; |
| Алексахина А. Ю. | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе; |
| Нургалиева Э. Ә. | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге начальнигы; |

ЗМР Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
25.09.2020 ел, №1829

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАРАГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карагуҗа авыл җирлегенең Генераль планы проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - комиссия) территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү өчен төзелә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген РФ Шәһәр төзелеше кодексы, башка норматив актлар нигезендә даими эшләп килә һәм тормышка ашыра.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Комиссия дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынучы юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлектә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы ЗМР Башкарма комитеты карары белән раслана.
2.2. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:
3.1.1. Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә территорияләрне эзлекле булдыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү;
3.1.2. Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;
3.1.3. «Зеленодольск муниципаль районының Олы Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм уздыру;
3.1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр җыела.

4.2. Комиссия утырышы, әгәр Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны комиссия утырышларында ике атна дәвамында карап тикшерүне тәэмин итә.

4.5. 4.4 пунктта күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә, ул беркетмәдә чагылдырыла.